

Боек Ватан сугышы ветераны, Ләмберә авылында туган, Кызыл Йолдыз һәм Ватан сугышы орденнары белән бvләкләнгән Билял Синятулла улы Мартыновнын язмышы турында беләбез. Әмма шушы коннәрдә генә анын кызы, Наилә Биляловна Максиняева (кыз чагында Мартынова), гаилә архивыннан иске әйберләрне һәм кәгазьләрне тикшергәндә, әтисенен тагын бер фотосын таба; анда әтисе, сенлесе һәм анын балалары белән сурәтләнгән була.
Бу фото хатын-кызнын хәтерендә кvптәнге вакыйгаларны уяткан. Әтисенен ничек истә калуы һәм аларнын гаиләсе сугыштан сонгы беренче елларда ничек яшәве турында Наилә Билял кызы “Призыв”ка сойләгән.
Боек Ватан сугышы...   Фронтка киткәндә әтиемә нибары унсигез генә иде. Черная елгасын кичкәндә авыр яралана, Ленинградтагы госпитальгә эләгә. Үтәли пуля ярасы, бу яра сугышчынын тәнендә гомеренен ахырына кадәр уч буе жой калдырган. Аягын ампутацияләгәннәр... кvпме газаплар, авыртулар һәм ометсезлекләр кичергән ул! Ләкин бу турыда әти бер дә искә тошерергә яратмый иде. Бервакыт, тыела алмыйча, блокададагы Ленинградта ниләр булганын энем белән безгә сойләп бирде. Ул бит блокада вакытында госпитальдә яткан, шуна кvрә карап туйган.
...Алжыган кешеләрнен коточкыч чиратларын оныту момкин тvгел иде. Ә тагын vзенен рәхимсезлеге буенча кыргый картина хәтеренә уелып калган: немец самолеты Ладога кvле бозы астына балалар белән машинаны жибәргән. Бозлы суга эләккән һәм нәрсә булганын анламаган сабыйларнын каты кычкыруыннан да куркынычрак нәрсә булуы момкин!..
Наилә Билял кызы, әтисе сойләгән истәлекләрне vзеннән читкә алып китәргә тырышкандай, бер-ике минутка уйга калды, аннары дәвам итте..: Әти ойгә протез белән кайтса да, колхозда эшли башлады. Председатель Ибраһим Али улы Маринов трактор бригадасына хезмәт кvрсәткән әтисен бик кадерли һәм хормәт итә иде. Әти аларга ботен кирәк-яракны ат белән алып кайткан. Сvз унаеннан, ул атларны бик яхшы белә, аларны карый белә иде. Ә тагын ул бик яхшы кvнелле һәм сабыр иде. Әниебез Хәлимә Шәрәфетдин кызы авырагач, ул аны гына карап калмады, безне, балаларны да кайгыртты. Безгә әнинен сенлесе дә ярдәм итте. Наиль абый белән абзар янында апабыз сыерыбызны савып алганны тvземсезләнеп котә идек. Остәвенә, рус мичендә яна пешкән ипи белән сот безнен очен ин тәмле ризык иде.
Ул чагында без бик тиз vстек, сугыш һәм сугыштан сонгы беренче еллар балалары! Ләкин әтием турында сойләгәндә, сугыш вакытында Нариманов исемендәге колхозда алдынгы тыл хезмәтчәннәре арасында булган, торле эшләр башкарган әнием турында да берничә сvз әйтәсем килә. Тик ул гына шулай эшли ала, дия иделәр барчасы. Тик авыру какшатты саулыгын…
Наиләгә уноч яшь тулуга, ул инде vзе сыер сава башлады; махсус тактага абыйсынын кvлмәкләрен, әтисенен һәм әнисенен киемнәрен ышкый-ышкый гаилә киемнәрен юган, бик тырышып сыер сауган.
- Ипи әчеткесен дә vзем әзерләдем, - дип искә ала Наилә Билял кызы. Әни кочкә генә

булса да, караватыннан торып, остәл янындагы эскәмиягә утырып, мина нишләргә кирәклеген ойрәтеп калдырды. Шул ук вакытта: «...кулларын нечкә булса да кочле, опаран яхшы чыга», - дип мактаудан туктамады. Әлбәттә, ипине мичкә куярга минем кочем житмәде, кvрше хатын булышты.
… Наилә Билял кызынын әтисе дә ой буенча коченнән килгәннен барысын да эшләргә тырышты. Аннары, абыйсынын гаиләсе белән яшәгәндә, киленнәре булышты.…
Шунысы игътибарга лаек, әтисе укый-яза белмәгән, ана мәктәптә укырга туры килмәгән. Шуна да карамастан, ул кvп кенә крестьяннарга хас акылга ия булган, эшлекле кинәш бирә алган. Шул ук вакытта беркайчан да беркемне дә гаепләмәде, кvршеләрдән яки танышлардан берәрсе турында начар сvз әйткәнен хәтерләмибез.
Наилә Билял кызынын, әтисе белән әнисе vрнәген кvреп, кечкенәдән vк авыр крестьян хезмәтенә кvнеккән булуы гажәп тvгел. Семьяны бик тырышып караган, сыер асраган, ә бит топ эштә – Госбанкта анын эше кvп булган. Машинисткадан башлаган. Похтә итеп таратып салынган кәгазьләр, машинкада басылган битләр: компьютерлар турында ул чакта ишеткәннәре дә булмаган. Арыган, кайчакта артык киеренкелектән яшьләнә башлаган кvзләр, ә аннары кич белән - ой, хужалык мәшәкатьләре. Һәм иртән һаман янадан, шул ук корылган тvгәрәк буенча дәвам иткән. Әлбәттә, ире Няим Тажетдин улы булышырга тырышкан, ләкин анын РайПО эшләре белән еш командировкаларга баруы авырга туры килгән. Шулай да Наилә Биляловна vткәннәрне искә тошереп, vз язмышыннан бер тапкыр да зарланмаган, киресенчә, балачак һәм яшьлек еллары турында ниндидер яшерен жылылык белән сойләгән. Кvрәсен, бу сыйфатлар да – сабырлык, әйләнә-тирәсендәге кешеләргә карата мәрхәмәтлелек, ул да әтисеннән мирас итеп алган.
Язмышларнын гажәеп vрелеше турында сойләгәндә, шушы факт бик тә урынлы: Ленинград блокадасы вакытында, авыр яралангангач, Билял Синятулла улы Мартынов дәвалану курсын Питер госпиталендә узган. Безнен коннәрдә ветеран-фронтовикнын кыз оныгынын ире, СВО катнашучы Ринат Таиров та сәламәтлеген Питер госпиталендә ныгытты.

**Наилә НАСЫРОВА** *әзерләде*
*Фотода: сугыш ветераны Билял Синятулла улы Мартынов сенлесе Фатыйма һәм анын балалары белән.*